**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** с.Базарные Матаки **КАРАР**

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 октябрендәге «2022-2027 елларга Татарстан Республикасы Әлки Муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» 376 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

№

2024 елның 26 февралендәге «Коммерциясез оешмалар турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 32-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 14 октябрендәге «2022-2027 елларга Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районында социаль юнәлешле коммерциясез оешмаларга ярдәм» муниципаль программасын раслау турында» Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 376 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) социаль хезмәт күрсәтү, гражданнарга социаль ярдәм һәм яклау, гаиләгә, аналарга, аталыкка һәм балаларга ярдәм итү өлкәсендәге эшчәнлек, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыруның Россия Федерациясе законнарында каралган рәвешләрен үстерүгә ярдәм итә торган чаралар оештыру һәм уздыру»;

2 бүлекнең 3 нче абзацы "сәяси партияләр" сүзләреннән соң "дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр" сүзләрен өстәргә.

2 бүлекнең 4 пунктчасында “, шул исәптән хайваннар приютында хайваннарны тоту” сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында”: http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Әлки муниципаль районы

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Х.Морадымов